**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2022 елның 28 марты** **30-РС номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 15 декабрендәге 59-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы, «Федераль дәүләт хезмәте Вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2009 елның 18 маендагы 559 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте Вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы , «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору өлкәсендәге аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-988 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән, «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында

белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 15 декабрендәге 59-РС номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаны, әлеге карарга кушымта нигезендәге редакциядә бәян итәргә.

2. Лаеш муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнарына шундый ук муниципаль норматив хокукый актлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль**
**район Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

*Татарстан Республикасы*
*Лаеш муниципаль районы Советының*
*2022 елның 28 мартындагы 30-РС номерлы*
*карарына кушымта*

**Муниципаль хезмәткә билгеләнгәндә гражданнар керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылырга тиеш булган, һәм аларны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр алыштырган очракта керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылырга тиеш булган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге.**

Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары, төп, әйдәп баручы һәм өлкән төркемнәре чикләрендә каралган, муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына кертелгән Муниципаль хезмәт вазыйфалары (Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2016 елның 13 декабрендәге 69-РС номерлы карары).

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**